ГЛАВА УРУССИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старые Уруссу, ул.Советская,
д.16в, , 423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Иске Урыссу авылы, Совет урамы,
16в йорт, 423960

Тел.:(85593) 4-42-31, факс: 4-41-52, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
N 5 16.11. 2020 ел.

Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пунктында 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Урыссу авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге башлыгы
К А Р А Р И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Байлар авылы, Тукай ур., 41 нче йорт адресы буенча урнашкан Байлар авыл мәдәният йорты бинасы янында 2020 елның 28 ноябренә 10.00 сәгатьтә Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Байлар торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш 2021 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә түләргә һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга ризамы:

- Октябрь урамы, Комсомол урамы буенча Байлар торак пункты юлларын норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, асфальт салу, ремонт, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Байлар торак пункты юлларын кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», www.yutaza.tatarstan.ru веб-адрес буенча - Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова